# ӘНКӘЙГӘ ТЕЛӘКЛӘР

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Бик тиз еллар үтте, куып бер берсен,
Балачак калды еракларда.
Ләкин әнкәйнең яшь чактагы төсе
Гел яши безнең йөрәкләрдә.

Елмаю нуры балкытсын йөзеңне,
Очыртсын борчу-кайгыларың!
Яшә, әнкәй, яшә, картайма мәңге,
Ямьле булсын алгы көннәрең!
} 2 тапкыр

2. Куарга теләп бар дөнья эшләрен,
Таралдык, киттек без еракка.
Тик йөрәгеңнең тылсымлы көчләре
Кайтарды безне туган якка.

Таң җилләре үпсен чәчләреңне,
Кошлар бүләк итсен көйләрен.
Яшә, әнкәй, яшә, картайма мәңге,
Ямьле булсын алгы көннәрең!
} 2 тапкыр

3. Балкысын кояштай нурлы йөзләрең,
Һич картаймасын синең йөрәк!
Безнең өчен, әнкәй, җылы сүзләрең,
Бар бүләкләрдән дә кыйммәтрәк!

Якты өметләр биләсен күңелеңне,
Сызламасын аяк-кулларың!
Яшә, әнкәй, яшә, картайма мәңге,
Ямьле булсын алгы көннәрең!
} 2 тапкыр

**Пожелания маме**

Песня написана ко дню рождения моей мамы Халиды Гарифовны. Посвящается всем матерям.

*В этот день прекрасный мы желаем снова:*
*Будь ты, мама, счастлива и всегда здорова!*
*Мы же, твои дети, будем с тобой рядом.*
*Только радуй, мама, нас своим ты взглядом!*